КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 апрель г.Казань № 306

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыныж аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 10 апрель, 272 нче, 2020 ел, 13 апрель, 280 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның г» пунктчасында:

«хезмәт күрсәтүдән тыш:» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның 20 апреленнән башлап чәчтараш хезмәтләре.»;

11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елның 20 апреленнән башлап, санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр, гражданнарның ваклап сату, хезмәт күрсәтү объектларына керүе һәм аларда булуы, җәмәгать транспортында сулыш органнарын индивидуаль яклау чараларыннан башка (битлекләр, ресираторлар) керүе һәм булуы.»;

12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән өстәргә:

«көн саен эш (смена) башланганчы хезмәткәрләрнең тән температурасын үлчәүне һәм аларда респиратор авыру билгеләре (томау, тамак төбе кычыту, ютәл) булуы турында сораштыруны үткәрергә;

тән температурасы югары булган, йогышлы авыру билгеләре булган затларның эшләвенә юл куймаска;

гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазларны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне вируса каршы дезинфекция чаралары кулланып дезинфекцияләүне гамәлгә ашырырга;

кискен респиратор-вируслы инфекцияләрне профилактикалау турында мәгълүмат урнаштырырга;

эш көне тәмамланганнан соң вируса каршы дезинфекция чаралары кулланып бүлмәләрне юешләп җыештырырга;

эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләреннән чыгып, санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чаралар күрергә.

Оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләргә гражданнар белән үзара эшләгәндә:

хезмәткәрләрнең шәхси саклану чараларын (битлек яки респираторлар, перчаткалар) һәм тире антисептикларын куллануын, шулай ук килүчеләр кулларын тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазларны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне дезинфекцияләү, вируска каршы дезинфекция чаралары кулланып, көнгә кимендә өч тапкыр башкара;

гражданнарны хезмәт күрсәтү максатларында кабул итү алдан язылу буенча, бер кабул итү тәмамланганнан соң икенче кабул итү башланганчы агымдагы дезинфекция һәм җилләтү үткәрү өчен 10 минуттан да ким булмаган вакыт арасында интервал белән, шулай ук бер үк вакытта кимендә 1,5 метр социаль дистанция сакланган санда клиентлар булуын тәэмин итү белән башкарыла.

Гражданнарга хезмәт күрсәтү шартлары турында дөрес һәм актуаль мәгълүмат алу максатыннан, халыкка чәчтараш хезмәтләре күрсәткәндә оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр «Интернет» челтәрендә онлайн-режимда мондый хезмәтләр күрсәтү шартларының видеосурәтен алырга мөмкинлек бирә торган җиһазлардан файдаланырга хокуклы. Шул ук вакытта закон таләпләрен үтәү, шул исәптән гражданның сурәтен саклау өлешендә, мондый җиһазлардан файдалану турында гражданнарга алдан хәбәр итүне һәм аларның сурәтен күрсәтүгә ризалыгын алуны да кертеп, тәэмин ителергә тиеш.»;

карарга 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чәчтараш хезмәтләре күрсәтүче оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр (чәчтараш хезмәтләре күрсәтү өлешендә).».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 13 апрель, 279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) чәчтарашханәдә булу.»;

уникенче абзацта «10 пунктта күрсәтелгән очрак» сүзләрен «10 һәм 11 пунктларда күрсәтелгән очраклар» сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карар 2020 елның 20 апреленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин